Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

2025 елның 15 октябре № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мамашир авыл җирлегенең Мәмәшир авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының 1 нче этабын 2025 елның 28 октябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә. Мәмәшир авылы, Яшьләр ур., 29Б йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

2. 2025 елның 15 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә. Мәмәшир авылы, Октябрь урамы, 48а нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

3.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: " Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдән,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәкләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2026 елда һәр бәлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен торак пункт чикләрендә ремонтлау

“ӘЙЕ” « КАРШЫ»

4.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

5. Халык җыенын Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г. Әхмәтҗанов

СОВЕТ МАМАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМӘШИР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ОГРН 1021607753012

ИНН 1623001702